Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Карасу авыл җирлеге составына керүче Карасу торак пунктта

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 27 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Карасу авыл җирлеге Карасу торак пунктында гражданнар җыены

Карар итте:

1. 2020 елда Аксубай муниципаль районының Карасу авыл җирлеге Карасу авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- кышкы чорда Карасу авылы эчендәге юлларны карап тоту.

Карасу авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Идиятуллин